КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 24 ноябрь г.Казань № 1260

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән расланган Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 июль, 524 нче; 2015 ел, 17 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 30 декабрь, 1140 нчы; 2020 ел, 15 июнь, 490 нчы; 2021 ел, 12 февраль, 73 нче; 2022 ел, 20 июнь, 591 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә Министрлык тарафыннан, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.»;

2.1 пунктының дүртенче абзацында «30 нчы» сүзләрен «10 нчы» сүзләренә алмаштырырга;

3.6 пунктның тугызынчы абзацында «субсидия бирү нәтиҗәләре һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр зурлыгы» сүзләрен «субсидия бирүне тәгәлләүнең төгәл датасы һәм аны бирү нәтиҗәсенең соңгы зурлыгы (йомгакларның төгәл микъдари тасвирнамәсе)»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Субсидия бирүнең планлаштырыла торган нәтиҗәсе – хисап аеннан соң килә торган айның 1 нче көненә карата инвалидларның сакланган, Субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән эш урыннары саны.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюдетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән расланган Инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюдетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 3.1 пунктындагы өченче абзацы һәм 3.2 пунктындагы бишенче абзацы гамәлен 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин